ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **К А Р А Р**

20.02.2025 | № 235

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының өстәмә гомуми үстерелеш һәм һөнәр алды программаларын гамәлгә ашырган «Салих Сәйдәшев исемендәге сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә муниципаль хезмәт күрсәтүләрне башкаруның административ регламентын раслау турында» 2021 елның 9 декабрендәге 996 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының өстәмә гомуми үстерелеш һәм һөнәр алды программаларын гамәлгә ашырган «Салих Сәйдәшев исемендәге сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә муниципаль хезмәт күрсәтүләрне башкаруның административ регламентын раслау турында» 2021 елның 9 декабрендәге 996 номерлы карары (25 октябрь, 2023 ел № 1626 карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының өстәмә гомуми үстерелеш һәм һөнәр алды программаларын гамәлгә ашырган «Салих Сәйдәшев исемендәге сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «3.6. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)» бүлеген түбәндәге эчтәлекле 3.6.4 - 3.6.5 пунктлар белән тулыландырырга:

«3.6.4. Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен балигъ булмаганның мөрәҗәгать итүче булып торган законлы вәкиле алганда, кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән

балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру балигъ булмаганның мөрәҗәгать итүче булмаган законлы вәкиле тарафыннан башкарылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле балигъ булмаганның башка законлы вәкиленең фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), шәхесен таныклаучы документы турында белешмәләрне күрсәтә.

3.6.5. Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазьдә язылган документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга язма рәвештә теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә тапшырыла алмый.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин